ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре,
420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ _17_

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«21» ____01___ 2020 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 09 апрелендәге 137 номерлы, 2018 елның 23 июлендәге 275 номерлы, 2019 елның 24 гыйнварындагы 31 номерлы, 2019 елның 24 июлендәге 280 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтадагы үзгәрешләрне расларга.
2. Юридик бүлек башлыгына (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны җитәкче урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С. Саттаровка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы В.И. Маряшев

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның 21 гыйнварындагы 17 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3 пунктта:

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтелергә яисә үзгәртеп корылырга тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмә раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 47 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 6, 702 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)»;

утыз бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 8, 1239 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);»;

егерме икенче һәм илле бишенче абзацлары үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.6 пунктта:

2 пунктчада «күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре ризалыгы белән торак урыннарга керергә һәм аларга тикшерүләр уздырырга» сүзләрен «күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре, социаль найм килешүләре буенча торак урыннарын наймга алучыларның, социаль файдаланудагы торак фондында торак урыннарын наймга алу килешүләре буенча торак урыннарын наймга алучыларның ризалыгы белән күпфатирлы йортта мондый урыннарга керергә һәм аларга тикшерүләр уздырырга» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның бишенче абзацында «милекчеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре» сүзләреннән алда «күпфатирлы йорттагы биналарның» сүзләрен өстәргә;

2 бүлектә:

2.10 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече

предприятие өчен – кырык сәгатьтән һәм микропредприятие өчен ун сәгатьтән артык була алмый. Инспекциянең тикшерү уздыра торган вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшеренүләрне һәм экспертизаларны уздыру зарурлыгына бәйле искәрмәле очракларда, тикшерү уздыру срогы озынайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата иң күбе – утыз сәгатькә һәм микропредприятиеләргә карата иң күбе – ун сәгатькә һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең башка резидентларына карата иң күбе – унбиш эш көненә кадәр.»;

2.13.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13.2. Планлы тикшерүне планлы тикшерүләр уздыруның еллык планына кертү нигезләре:

- әлеге көннән соң бер елның узып китүе:

1) торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки махсус кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган хәбәр нигезендә әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлаган көннән соң;

2) социаль файдаланудагы беренче найм йорты социаль файдаланудагы найм йортларының муниципаль реестрында исәпкә алынганнан соң, – андагы торак урыннарын наймга тапшыручы булып эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат торса;

3) коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары билгеләнгәннән соң яисә үзгәртелгәннән соң;

- ТР Министрлар Кабинетының 128 номерлы карары нигезендә юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлеге кертелгән тиешле хәтәрлек категориясе өчен билгеләнгән планлы тикшерүне уздырган елда соңгы планлы тикшерүне тәмамлау датасыннан соңгы вакыт чорының узып китүе.»;

2.20 пунктта «әлеге Регламентка 3 нче кушымтада» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 128 нче карарында» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 1 таблицасында:

«Милек рәвешенә бәйсез рәвештә торак фондыннан файдалану һәм аны саклау» юлындагы икенче графада беренче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урын гражданнарга яшәү өчен билгеләнгән.

Торак урыннарда сәнәгый производстволар, кунакханәләр урнаштыру, шулай ук торак урыннарда миссионерлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру рөхсәт ителми, «Намус иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясында каралган очраклардан тыш. Күпфатирлы йорттагы торак бина кунакханә хезмәтләрен күрсәтү өчен файдаланыла алмый»;

«Торак фондын исәпкә алу» юлындагы өченче графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Элемтә министрлыгының 74 номерлы, Россия Төзелеш министрлыгының «Торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр тарафыннан урнаштырыла торган мәгълүматның составын, аны урнаштыру срокларын һәм вакытын раслау турында» 2016 елның 29 февралендәге 114/пр номерлы боерыгы;

«Социаль файдаланудагы найм йортларында торак урыннары бирү» юлында:

икенче графаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Найм йортлары белән идарә итү РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-1.2, 15 һәм 16 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, мондый йортта торак урыннарын наймга бирүчеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла, әгәр мондый йортның яисә андагы биналарның милекчесе тарафыннан мондый йорт белән идарә итүнең РФ Торак кодексының 162 статьясы нигезендә милекче яисә ул вәкаләт биргән наймга бирүче белән төзелгән идарә итү килешүе буенча РФ Торак кодексының 161 статьясының 2.3, 9 һәм 10.1 өлешләре нигезендә идарәче оешма тарафыннан гамәлгә ашырылуы турында карар кабул ителмәгән булса»;

өченче графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

РФ Торак кодексының $91^{20}$ статьясының 1 өлеше»;

«Күпфатирлы йортлар белән идарә итү килешүләрен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итүне, шул исәптән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тотуны һәм ремонтлауны тәэмин итүче башка килешүләрне, коммуналь хезмәтләр күрсәтү шартларын үз эченә алган килешүләрне һәм күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми мөлкәтеннән файдалану турындагы килешүләрне төзү тәртибе һәм шартлары» дигән юлда икенче графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүендә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

күпфатирлы йортта идарә ителәчәк гомуми мөлкәтнең составы һәм мондый йортның адресы;

күпфатирлы йорт белән идарә итү буенча эшләр һәм (яки) хезмәтләр, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр һәм эшләр исемлеге, мондый исемлекне үзгәртү тәртибе, шулай ук идарәче оешма күрсәтә торган коммуналь хезмәтләр исемлеге, РФ Торак кодексының $\underline{157}^{2}$ статьясы нигезендә күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләрдән тыш;

килешү бәясен, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе, шулай ук мондый түләүне кертү тәртибе, РФ Торак кодексының $\underline{157}^{2}$ статьясы нигезендә күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләр өчен түләүдән тыш;

идарәче оешманың идарә килешүе буенча үз йөкләмәләрен үтәвенә контрольлек итү тәртибе.

Күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүендәге шартлар күпфатирлы йорттагы биналарның барлык милекчеләре өчен дә бертөрле билгеләнә.»;

4 бүлектә:

7 пунктта «Документ формасын билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары».

5 бүлектә:

5.75 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инспекция вәкаләтләренә караган административ хокук бозулар турындагы эшләр турыдан-туры җаваплы башкаручының җитәкчесенә тапшырыла, ул аларны

өйрәнгәч һәм аларга виза салганнан соң, карап тикшерүне оештыру өчен, аларны җаваплы башкаручыга кире тапшыра;»;

«Административ хокук бозу турындагы эшне карау» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.77. Карау өчен килгән административ хокук бозу турында беркетмә административ хокук бозу турында эшне карый башлау өчен нигез булып тора.

Административ хокук бозу турындагы эшне карау Административ хокук бозулар турында РФ кодексы таләпләренә туры китереп башкарыла.

5.78. Дәүләт торак инспекторының турыдан-туры җитәкчесе өч эш көне эчендә алынган материалларны карый, виза сала һәм, документларны рәсмиләштерүдә хаталар булмаган очракта, административ хокук бозу турындагы эшне карау вакытын һәм урынын билгеләү һәм мәнфәгатьле затларны чакырту өчен, материалларны дәүләт торак инспекторына кире кайтара.

5.79. Беркетмәне төзү һәм башка материалларны рәсмиләштерү моңа хокукы булмаган затлар тарафыннан гамәлгә ашырылганда, беркетмә дөрес төзелмәгәндә һәм башка материаллар дөрес рәсмиләштерелмәгәндә яисә тапшырылган материаллар тулы булмаса, эшне караган вакытта аларны тулыландыру мөмкинлеге булмаган очракта административ хокук бозу турындагы беркетмә һәм башка материаллар, әлеге Регламентка 11 нче кушымтада китерелгән форма буенча беркетмәне һәм эшнең башка материалларын кире кайтару турында мотивацияле һәм бетерүне таләп итә торган җитешсезлекләр ачыклануына күрсәтә торган билгеләмә чыгару юлы белән, җитешсезлекләрне бетерү өчен дәүләт торак инспекторына кайтарыла.

5.80. Кисәтүләр дәүләт торак инспекторы тарафыннан өч эш көненнән артмаган вакыт эчендә бетерелә.

5.81. Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасында китерелгән форма буенча төзелгән административ хокук бозу турындагы эшне карау вакытын һәм урынын билгеләү һәм затларны чакырту турындагы билгеләмәгә кул куя.

Административ хокук бозу турындагы эшне карау вакытын һәм урынын билгеләү турында билгеләмәне дәүләт торак инспекторы җибәрә.

5.82. Административ эшне карап тикшерүне Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) административ хокук бозу кылынган урын буенча эшне карап тикшерүгә тапшыру көненнән башлап, эш буенча карарның хокук бозу башкарылган вакыттан алып ике айлык чордан соңга калмыйча чыгарылган булырга тиешлеген исәпкә алып, 15 көнлек чорда гамәлгә ашыра.

5.83. Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 24.5 статьясында каралган шартлар булганда, биш эш көне эчендә административ хокук бозу эшен туктату турында карар чыгарыла, аны дәүләт торак инспекторы әзерли.

5.84. Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 4.5 статьясында билгеләнгән административ җаваплылыкка тарту буенча дәгъва белдерүнең ике айлык чоры узып киткәнчегә кадәр эш каралган, ә аның буенча карар кабул ителгән булырга тиеш. Шушы вакыт узып китү белән гаепле зат административ җаваплылыкка тартылмый, ә эш карар чыгару юлы белән туктатылырга тиеш, әлеге карарны дәүләт торак инспекторы әзерли.

5.85. Административ хокук бозу турындагы эш үзенә карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган зат, зыян күргән зат һәм Административ хокук бозулар турында РФ кодексында административ хокук бозу турындагы эшне карауда катнашырга рөхсәт ителгән башка затлар катнашында карала.

5.86. Эш әлеге Регламентның 5.85 пунктында күрсәтелгән затлар булмаганда каралырга мөмкин, фәкать түбәндәге очракларда гына:

эшне карау урыны һәм вакыты турында аларга тиешенчә хәбәр итү турында язмача белешмәләр булганда, шулай ук алардан эшне карауны кичектереп тору турында үтенеч язуы килмәсә;

эш материалларында эшне алар катнашыннан башка карау турында гозер булса.

5.87. Эшне карау кичектерелергә мөмкин. Эш карауны кичектерү турындагы карар әлеге Регламентның 12 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча төзелгән билгеләмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

Дәүләт торак инспекторы карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә эшне карауны кичектерү турында бәяләмә әзерли һәм эшне карауда катнаша торган затларга, шул исәптән эш алып барыла торган күзәтчелек объектының җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына, вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып, күчермәсен тапшыру юлы белән яки эшне карауны кичектерү турында карар кабул ителгән көннән башлап өч көн эчендә әлеге затларга тапшыру турында белдерүле заказлы хат итеп җибәрә.

5.88. Эшне карауны дәвам иттерү турында карар кабул ителгән очракта, эшне карауда катнашучы затларга аларның Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 25.1-25.10 статьяларында каралган хокуклары һәм бурычлары турында аңлатыла.

5.89. Эшне карау йомгаклары буенча Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан административ хокук бозу эше буенча карар чыгарыла, ул эшне карап бетерү белән әлеге Регламентның 13 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә кичекмәстән игълан ителә.

Административ хокук бозу эше буенча карар күчермәсе дәүләт торак инспекторы тарафыннан үзләренә карата шушы карар чыгарылган күзәтчелек объектының җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына, вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып, шулай ук зыян күргән затка аның гозере буенча тапшырыла яисә күрсәтелгән затларга әлеге карар чыгарылган көннән башлап өч көн эчендә кулга тапшыру турында белдерүле хат итеп җибәрелә.

5.90. Зат бер яисә аннан күбрәк административ хокук бозган очракта, кылынган һәр административ хокук бозу очрагы өчен Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан административ җәза билгеләнә.

Зат тарафыннан административ хокук бозу составына керә торган бер гамәл кылынганда (гамәл кылынмаганда), аның өчен Административ хокук бозулар турында РФ кодексының ике һәм аннан күбрәк статьясында (статьялары өлешләрендә) җаваплылык каралганда, административ җәза әлеге гамәлне кылган (гамәлне кылмаган) затка билгеләнергә тиешле тагын да катырак административ җәза санкцияләре кысаларында билгеләнә.

5.91. Административ хокук бозу сәбәпләре һәм аны кылуга сәбәпче булган шартлар ачыкланган очракта, тиешле оешмалар һәм вазыйфаи затлар адресына күрсәтелгән сәбәпләрне һәм шартларны юкка чыгару буенча чаралар күрү турында

Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан йогынты акты чыгарылырга мөмкин, ул дәүләт торак инспекторы тарафыннан рәсмиләштерелә. Йогынты акты Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалана. Йогынты актының күчермәсе административ эшкә теркәп куела.

5.92. Йогынты актында административ хокук бозу сәбәпләрен һәм моңа сәбәпче булган шартларны юкка чыгару чараларын күрү турында таләп, хокук бозучының йогынты актын алган көннән бер ай эчендә карап тикшерү бурычы һәм йогынты актын чыгарган вазыйфаи затка күрелгән чаралар турында хәбәр итү бурычы күрсәтелергә тиеш.

Күрсәтмәдә күрсәтелгән таләпләрнең үтәлешен беркетмә төзегән дәүләт торак инспекторы контрольдә тота.

5.93. Йогынты актын кабул итүдән һәм аңа имза салудан баш тарту аны чыгару өчен, шулай ук билгеләнгән чорларда аның таләпләрен үтәүгә каршылык була алмый.

5.94. Йогынты актын билгеләнгән вакытында үтәмәгән очракта акт белән беркетмә төзелә, алар административ җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тора.

5.95. Административ хокук бозу эшен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекциянең вазыйфаи затлары тарафыннан түбәндәгечә карар чыгарылырга мөмкин:

административ җәза билгеләү турында;

административ хокук бозу турындагы эшне туктату турында.

5.96. «Тикшерүләр уздырганда ачыкланган хокук бозу фактларына карата чаралар күрү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәләре:

1) ачыкланган хокук бозуны юкка чыгару турында күрсәтмә, тикшерү актына кушымта булып тора;

2) административ хокук бозу турында беркетмә;

3) административ хокук бозу турындагы эш материаллары;

4) карар:

административ җәза билгеләү турында;

административ хокук бозу турындагы эшне туктату турында;

5) административ процедура нәтиҗәләре турында Тикшерүләрнең бердәм реестрына, Торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән белешмәләр».»;

7 бүлектә:

7.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Мөрәҗәгать итүчедән (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән яисә почта аша, Инспекциянең tatgi@tatar.ru электрон адресы, яисә Инспекциянең www.gji.tatarstan.ru рәсми сайтындагы Интернет-кабул итү системасы аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә Инспекциягә мөрәҗәгать (шикаять) килү судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлап җибәрү өчен нигез була.

Электрон документ рәвешендә кергән шикаятьтә мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яисә оешманың тулы атамасы, җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы, мөрәҗәгатьне башка адреска җибәрү турында хәбәр булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче мондый шикаятькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада теркәргә хокуклы.

Инспекция башлыгына телдән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгатькә (шикаятькә) җавап, мөрәҗәгать иткән затның ризалыгы белән, шәхси кабул итү барышында бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү карточкасында язу теркәлә. Телдән мөрәҗәгатьнең эчтәлеге шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү карточкасына теркәлә. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача рәвештә җавап бирелә.»;

7.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Әгәр язмача шикаятьтә юридик затның атамасы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда), шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр бу шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасыз яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, шикаять анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты аңлаешлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы аңлаешлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Язмача шикаятьтә аның асылы буенча элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җавап бирелгән сорау бәян ителсә һәм, шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, Инспекция башлыгы, Инспекциянең вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле заты, әлеге шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең Инспекциягә яисә Инспекциядәге шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаять белән мөрәҗәгать итүнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән мондый язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Инспекциягә яки Инспекциянең вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, Инспекциянең «Интернет»

челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алган язма шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәргән затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган Инспекциянең рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил иткән белешмәләрне таратмыйча гына җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап биреп булмавы турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне Инспекциягә яисә аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.»;

Регламентның 3 нче кушымтасын көчен югалткан дип танырга;

Регламентка 7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 7нче кушымта

| ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

**тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru**

Район ____________________ Торак пункты ________________________

КҮРСӘТМӘ № ______

«__» ________ 20__ ел.

Бирелде_____________________________________________________________________________
(юридик затның атамасы, адресы яки физик затның, вазыйфаи затның, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_____________________________________________________________________________
(физик зат – Ф.И.А., яшәгән урыны, эш урыны, туган көне, ае, елы)

Тикшерү объекты: урам ____________ йорт № _____ корп. № ____ ф. № ____
Объектка сыйфатлама: материал: стеналар _____________, түбә _____________;
катлар _____, саны: бүлемтекләр ________, фатирлар _________; гомуми мәйданы (кв. м) _________, файдалануга тапшыру елы - _______.
Тикшерү үткәрелде:
_____________________________________________________________________________буенча
(объект буенча тулаем алганда, бүлемтек, фатир, подвал, түбә, йорт яны терр. һәм башкалар)

_______________________________________________буенча тикшерелгән мәйдан _____ кв. м.
(сәбәбен күрсәтергә: график буенча, шикаять нигезендә һ.б.)

Хокук бозулар ачыкланды: Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы карары белән расланган Торак биналардан файдалану кагыйдәләре, Россия Дәүләт төзелеш күзәтчелегенең 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары, Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Ведомство төзелеш нормалары, РФ Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре һ.б.

| № п/п | Норматив документның пункт номеры | Хокук бозуга сыйфатлама | Эшләрнең исемлеге һәм атамасы | Бетерү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

____ б. нигезләмәне кар.

Әлеге күрсәтмәне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта юридик зат, вазыйфаи зат, гражданин Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.5 статьясының 1 өлеше нигезендә административ җаваплы була.

Дәүләт торак инспекторы ____________________ ________________________________
(имза) (Ф.И.А.)

Күрсәтмәне алдым ____________________ ________________________________
(имза) (Ф.И.А., вазыйфа)

Тикшерүдә катнашучылар:

________________________________________ ________________
(Ф.И.А., вазыйфа, оешма) (имза)

________________________________________ ________________
(Ф.И.А., вазыйфа, оешма) (имза)

Махсус тамгалар:

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

## № ______ КҮРСӘТМӘГӘ
кушымта

«__» ________ 20__ ел.

| Тәртип саны | Норматив документның пункт номеры | Хокук бозуга сыйфатлама | Эшләрнең исемлеге һәм атамасы | Бетерү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Дәүләт торак инспекторы ______________________ ___________________________________
(имза) (Ф.И.А.)

Күрсәтмәне алдым ______________________ ___________________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме, вазыйфа)».